Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Иске Илтерәк авыл җирлеге башлыгы

# КАРАР

19.10. 2020 ел.

№4

Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлегенең
Чуаш Енорускино авылында халык җыенын гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе
буенча билгеләп кую турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.11.2003 ел, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районы «Иске Илтерәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә,
КАРАР БИРӘМ:

1. ТР, Аксубай районы, Чуаш Енорускино авылы, Ленин урамы, 18а йорт адресы буенча урнашкан КФҮ бинасында 2020 елның 29 октябрендә 10 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Чуаш Енорускино авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының **беренче этабын билгеләргә**.
2. ТР, Аксубай районы, Чуаш Енорускино, Ленин урамы, 18а йорт адресы буенча урнашкан КФҮ бинасында 2020 елның 29 октябрендә 13 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Чуаш Енорускино авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының **икенче этабын билгеләргә**.

3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлегенең Чуаш Енорускино авылында яшәүчеләр исемлеген 2 өлешкә бүләргә:

1) Көнчыгыш ур., Урман ур., Төньяк ур.;

2) Южная ур., Школьная ур., Садовая ур., Школьная тыкрыгы, Полевая ур., Пионерская ур.;.

4. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган торучыдан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2021 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән **сез риза буласызмы?**

**1) Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**
- вак таш капламалы поселок эчендәге юлларын чокырлы ремонтлау (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
-вак таш капламлы юл полотносы урнаштыру, грунт салу, юл капламын тигезләү (грейдирование), вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү, вак таш сатып алу);
- авыл эчендәге автомобиль юлларын кышкы чорда торак пунктта тоту (килешү буенча эш өчен түләү).

**2) Әлеге кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

- контейнер мәйданчыклары төзү (материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү),
- җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, трактор чапкычына запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ».

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, әлеге карарны авыл җирлеге халкы күплэп җыела торган урыннарда, стендларда һәм такталарда элеп кую юлы белән, шулай ук Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

6.Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

ТР Аксубай муниципаль районы

Иске Илтерәк авыл җирлеге башлыгы: С. М. Маклаков